**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ____________ КАРАР _______

2019 елда Актаныш муниципаль районы территориясендә язгы ташуга әзерлек һәм аны үткәрү буенча оператив җитәкчелекне тәэмин итү чаралары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен яклау чаралары турында» 2019 елның 11 февралендәге 92 нче номерлы карарын үтәү йөзеннән **КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районының су басуга каршы тору комиссиясе һәм эш төркеме составын Актаныш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгы комиссиясе каршында 2019 елда су ташу суларын чыгару гамәлләрен тикшереп торуны һәм координацияләүне тәэмин итү буенча расларга. (1 нче кушымта);

2. «ТР буенча 15 ФПС отряды» ПСЧ-103 ФГКУ башлыгына Актаныш муниципаль районының 2019 елның язгы чорында язгы ташу күренешләренә бәйле гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү планын эшләүне һәм раслауны оештырырга;

3. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләренә һәм авыл җирлекләре башлыкларына:

- су басуга каршы комиссияләр төзергә һәм язгы ташуны әзерләү һәм үткәрүнең конкрет планын эшләргә;
- йорт түбәләрен кар һәм боздан чистартуны оештырырга;

4. Авыл җирлекләре башлыкларына:

- халык белән йорт тирәләрен, су үткәргеч торбаларны өй тирәләрен кардан чистарту һәм базлардан үз вакытында азык-төлекне чыгару, шулай ук кечкенә елгаларның тар урыннарында һәм күперләр каршында агач һәм куакларны кисү буенча эш башкарырга;
- Аккүз авылы, Меңнәр авылы, Яңа Байсар авылы һәм Аеш авылы территорияләрендә язгы ташуны үткәрү буенча махсус режим урнаштырырга һәм елгаларда су өсте тигезлеген тикшереп торырга;

5. «Яран» торак милекчеләре ширкәте директорына күпкатлы торак йортлардан кар суларын һәм яңгыр суларын чыгару эшләрен оештырырга;

6. «Таттелеком» ААҖ Яр Чаллы электр станциясенең Актаныш РУЭС башлыгына барлык торак пунктларны оператив телефон элемтәсе белән тәэмин итәргә, авария бригадаларын һәм гадәттән тыш хәл нәтиҗәләрен бетерү техникасын югары әзерлектә тотарга;

7. «Татавтодор» ААҖ Минзәлә филиалының «Актаныш» ДРСУ башлыгы, «Актаныш юллары» ҖЧҖ, барлык суүткәргеч торбаларны, күперләрне һәм юлларны чистартуны оештырырга, экстремаль ситуацияләрдә эш итү өчен кирәкле техниканы һәм формированиеләрнең шәхси составын даими әзерлектә тотарга, шулай ук авария-

торгызу эшләрен башкару өчен ком, вак таш, ягулык-майлау материаллары һәм башка материаллар запасы булдырырга;

8. Актаныш районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгына авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә терлекләрне, орлык фондын, фуражны, минераль ашламаларны, техниканы һәм башка җайланмаларны яклауны кичектергесез чаралар күрүне, терлекчелек һәм склад биналарының түбәләрен һәм стеналарын, шулай ук хуҗалыклар территориясендәге су үткәрү торбаларын һәм күперләрен кардан чистартуны оештыруны, авария-торгызу эшләрен башкару өчен төзелеш материаллары, ягулык-майлау материаллары резервын булдыруны йөкләргә;

9. Районның авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә кирәкле азык, фураж, салам запасы булдырырга, 1-1,5 айга исәпләп, буш яткан җирләрдә кирәкле күләмдә азык запасы булдырырга;

10. «Түбән Кама электр челтәрләре, Актаныш РУЭСы» җитәкчесенә электр белән тәэмин итү линияләрен, мөмкин булган су басу зонасына эләккән трансформатор подстанцияләрне тикшерергә, аларны имин эксплуатацияләү буенча чаралар күрергә, авария бригадалары һәм техника составын югары әзерлектә тотарга;

11. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Чаллы шәһәре, Актаныш, Тукай, Мөслим, Минзәлә районнары һәм Яр Чаллы шәһәрендәге территориаль бүлеге башлыгы урынбасарына СанПиН нигезендә җитештерү контроле кысаларында су сыйфатына даими контроль ясарга; эчә торган суның сыйфатын лаборатория тикшеренүләре өлешендә эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан җитештерү контролен үткәрүне контрольдә тотарга;

12. «Актаныш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибына экстремаль хәлләрдә халыкка беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен җирле учреждениеләрнең, җаваплы хезмәткәрләрнең исемлеген билгеләргә, куркыныч зоналар янында медикаментларның кирәкле запасын булдырырга;

13. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгына оператив төркемнәр булдырырга һәм халыкка куркыныч янау турында кисәтү һәм хәбәр итү, шулай ук район буенча тәртип саклау буенча һәрьяклап ярдәм күрсәтергә;

14. Район газ эксплуатацияләү хезмәте башлыгына, «Актаныш РЭГС» су киртәләре һәм чокырлар аша газ торбаларының кучешләрен тикшерергә, кирәкле материал запасын булдырырга;

15. Түбән Кама сусаклагычын эксплуатацияләү участогы башлыгына насос станцияләренең тәүлек буе эшләвен тәэмин итәргә, мөмкин булган гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен кирәкле матди ресурслар резервын булдырырга;

16. Милек формаларына бәйсез рәвештә, буалар һәм плотиналар булган оешмалар җитәкчеләренә, «ПМК-6 " ҖЧҖ эш төркеме белән берлектә, су басуларны үткәрү өчен сулыкларны алдан ук әзерләргә;

17. «Татарстан Республикасы буенча 15 ФПС отряды» ФДХКУның ПСЧ-103 бүлеге башлыгына һәм район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә, шулай ук авыл башлыкларына янгын сүндерү техникасын, су суырту чараларын, мотопомпаларны һәм су баскан биналардан су суыртканда куллану өчен башка чараларны югары әзерлеккә китерергә;

18. «Актаныш» ҖБ җитәкчесенә зыян күргән халыкка ярдәм күрсәтү өчен кирәкле азык-төлек, он, кием-салым һәм урын кирәк-яраклары запасы булдырырга, халыкны җылыту һәм ашату буенча күчмә пунктлар оештырырга;

19. «Актаныш РДВБ» район территориясендә терлек каберлекләренең торышын даими тикшереп торырга;

20. Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә кирәк булганда ялгыз, өлкән яшьтәге гражданнарны, шулай ук язгы ташу вакытында пенсия яшендәге гражданнар һәм инвалидларны карауны оештырырга;

21. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә, мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына балалар тормышының иминлеген һәм сакланышын тәэмин итү буенча кирәкле чаралар күрергә, шулай ук ялгыз, өлкән яшьтәге гражданнарга, шулай ук язгы ташу вакытында пенсия яшендәге гражданнарга һәм инвалидларга ярдәм күрсәтергә;

22. Язгы ташуга каршы барлык комиссияләргә, 2019 елның 18 мартыннан башлап, көн саен (иртән һәм кичен) Сөн елгасы һәм Биҗады елгасының яр буе полосасы буенда су дәрәҗәсенең торышы турында 3-12-30, 01 телефоннары буенча мәгълүмат бирергә.

23. «Актаныш муниципаль районы» Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елда Актаныш муниципаль районы территориясендә язгы ташуга каршы чараларны әзерләү һәм үткәрү белән оператив җитәкчелек итүне тәэмин итү чаралары турында» 2018 ел, 22 февраль, ПР-31 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

24. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында үз көченә керә.

25.Әлеге карарны контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш.Бариев

Актаныш муниципаль районының су басуга каршы комиссиясе

| | |
|---|---|
| Бариев И. Ш. | - Башкарма комитет җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Шәрифҗанов И.И. | - комиссия рәисе урынбасары, «Татарстан Республикасы буенча 15 ФПС отряды» ФДКУның ПСЧ103 бүлеге башлыгы |
| Гарипов Р.И. | - комиссия рәисе урынбасары, инфраструктура үсеше буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары; |
| Хәмитов Р. Р. | - Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ГО өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты (Актаныш МР буенча). |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әмирҗанов Р. М - | - «Әлмәтгаз» эксплуатация-җитештерү идарәсенең район газ хезмәте башлыгы; |
| Ялалов И. Н. | - Актаныш РДВБ башлыгы; |
| Кустова Р. З | - «Коммунсервис Актаныш» ҖЧҖ директоры; |
| Фәрдиев Р.Т. | - «Яран» ТМШ директоры; |
| Нагимов ДА. | - «Теплосервис» ҖЧҖ директоры; |
| Хаев ХР. | - баш табиб «Актаныш үзәк район хастаханәсе» |
| Хәйретдинов И.И. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы; |
| Идрисов Р.И. | - «Татавтодор» ААҖ Минзәлә филиалының ремонтлау-төзелеш идарәсе башлыгы; |
| Гаязов Р.А. | - «Актаныш юллары» ҖЧҖ башлыгы; |
| Хаернасов Р. Ф. | - район электр элемтәсе челтәре башлыгы; |
| Хафизова Л.М. | - Яр Чаллы шәһәре «Роспотребнадзор» территориаль бүлек җитәкчесенең Актаныш районы буенча урынбасары; |
| Шакиров АЗ. | - «Актаныш АТХ» МУП директоры; |
| Шакиров М. М. | - Түбән Кама электр челтәрләре «Сетевая компания» ААҖ Актаныш районы электр челтәре башлыгы; |
| Шафикова НР. | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Харисов Д.А. | - авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы; |
| Нургалиев Ф.О. | - «Актаныш» кулланучылар җәмгыяте башлыгы; |
| Минһаҗев Ф.Г. | - УЭНКВ башлыгы; |
| Нурымов Х.Я. | - ХПП җитәкчесе; |
| Гәрәев Д. Ф. | - ПМК-6 җитәкчесе; |

*Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган затлар килештерү комиссиясе составына кертелә.